Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

**« 28» сентябрь 2016 ел** **№43**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә Арча шәһәр Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында Арча шәһәр Советының 20.07.2010 №464 карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Арча шәһәр Советының 09.04.2013 № 68 карары, Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Арча шәһәр Советының 31.07.2008 №397 карары, Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Арча шәһәр Советының 31.03.2015 ел, № 42 карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Р.Р. Мамаделеевага йөкләргә.

“Арча шәһәре” муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев